ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 06 2019 г. № 308

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 декабрендәге 1031 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы (балалар бакчалары) мәгариф учреждениеләренә (оешмаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491-нче карарына таянып, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 декабрендәге 1031 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы (балалар бакчалары) мәгариф учреждениеләренә (оешмаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.4. пунктында «4 айга кадәр срокка» сүзләрен «2 айга кадәр срокка» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6. пунктын түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:

«бала туу турында таныклык, ташламаларны раслаучы документлар:

күпбалалы гаилә балалары;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнар балалары;

инвалид балалар;

ата-ананың берсе булса да инвалид булган гаиләләр»;

3 бүлекнең 3.4. пункты 3.4.4. пунктчасына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Ташламаның гамәлдә булу срогы чыкканнан соң, мөрәҗәгать итүчегә Оешмага чираттан тыш яки беренче чиратта кабул итү хокукын расларга кирәк.»;

3 бүлекнең 3.4. пункты 3.4.6. пунктчасы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Уку елы дәвамында буш урыннар булганда, Оешмаларны Административ регламентның 3 пунктында каралган тәртип нигезендә комплектлаштырып бетерү үткәрелә.»;

3 бүлекнең 3.4. пункты 3.4.6. пунктчасы дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

3 бүлекнең 3.4. пункты 3.4.6.пунктчасы алтынчы абзацында «5 эш көненнән дә артык түгел» сүзләрен «бер эш көненнән дә артык булмаган» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.5. пункты 3.5.2 пунктчасының өченче абзацында «3 ай эчендә» сүзләрен «Бер ай эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.5. пункты 3.5.4. пунктчасы беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Теләгән кабул итү датасын юлламадан баш тарту турында мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган датага алыштыру башкарыла.»;

3 бүлекнең 3.5. пункты 3.5.5 пунктчасының беренче абзацында «Оешма җитәкчесе мөрәҗәгать итүчегә Системада «Килмәде» дигән статус бирә» сүзләрен «Системада гаризага «Килмәде» дигән статус бирелә» дигән сүзләргә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.5. пункты 3.5.6 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Раслаганда теләгән кабул итү датасын муниципаль хезмәт алуга ихтыяҗны раслау белән Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган вакытка үзгәртү башкарыла.»;

3 бүлекнең 3.6. пункты 3.6.2. пунктчасының икенче абзацында «3 айлык срок» сүзләрен «айлык срок» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.6. пункты 3.6.3. пунктчасының беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Раслаганда теләгән кабул итү датасын муниципаль хезмәт алуга ихтыяҗны раслау белән Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көннән дә иртәрәк булмаган вакытка үзгәртү башкарыла.»;

5.1. пунктының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә гамәлләр башкару таләбе»;

5.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:

«10) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтү. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү аның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә муниципаль хезмәтләр алу өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү бирү функциясе йөкләнгән очракта мөмкин.»;

5.9. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, мөрәҗәгать итүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яки оешма эшчәнлеге турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү алу максатларында алга таба башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

5 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 5.10. пункты белән тулыландырырга:

«5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында дәлилләнгән аңлатмалар бирелә.».

2. Җәмәгатьчелек һәм гаммәви мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р.Фәретдиновка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов